# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 декабрендә
кабул итылде

**1 статья**

2009 елның 13 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле $141^1$ статья өстәргә:

"$141^1$ статья. **Үз йөкләмәләрен түләүле нигездә үтәүче опекуннарга һәм попечительләргә тиешле түләү**

1. Үз йөкләмәләрен түләүле нигездә үтәүче опекуннарга яисә попечительләргә тиешле түләү Татарстан Республикасында һәр опекага алынган бала өчен 2500 сум күләмендә билгеләнә.

2. Өч яшькә җитмәгән һәр опекага алынган бала, йә инвалид бала, йә психик яисә физик үсешендә җитешсезлек булган бала, йә девиант холыклы бала өчен әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән түләү күләме 30 процентка арттырыла.

3. Педагогик яисә медицина белеме булган опекуннарга яисә попечительләргә әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән түләү күләме хезмәт өчен түләүнең федераль законда билгеләнгән минималь күләменең 50 процентына тигез суммада арттырыла.

4. Опекуннар яисә попечительләр теләге буенча түләүнең тиешле суммасы опекуннарның яисә попечительләрнең берсенә йә опекуннарның яисә попечительләрнең икесенә дә алар билгеләгән пропорциядә түләнергә мөмкин. Опекуннар яисә попечительләр белән килештерелгән түләүне бүлү опеканы яисә попечительлекне гамәлгә ашыру турындагы шартнамәдә күрсәтелә.

5. Опекуннарга яисә попечительләргә түләү чыгымнары законнар нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары һәм башка акчалар исәбеннән башкарыла.

6. Җирле үзидарә органнары опекуннарга яисә попечительләргә җирле бюджетлар акчалары исәбеннән өстәмә түләү билгеләргә хокуклы.";

2) 146 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"146 статья. **Тәрбиягә бала алучы ата-аналарга тиешле түләү**

1. Тәрбиягә бала алучы ата-аналарга (атасына йә анасына) тиешле түләү Татарстан Республикасында әлеге Кодексның $141^1$ статьясында билгеләнгән күләмнәрдә һәм тәртиптә башкарыла.

2. Җирле үзидарә органнары тәрбиягә бала алучы ата-аналарга җирле бюджетлар акчалары исәбеннән өстәмә түләү билгеләргә хокуклы.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 25 декабре
№ 104-ТРЗ